**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апрель, 2025 ел № 226-п

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү
буенча гарантияләүче оешманы һәм аның
эшчәнлек зонасын «Водоканал» ЖЧЖ
билгеләү турында»

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2001 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 12 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Яшьлек» торак комплексы территориясендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең 2024 елның 25 мартындагы 41 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су түгү схемасы нигезендә, Көек авылының төньяк-көнбатышында урнашкан салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү үзәкләштерелгән системасы өчен гарантияле оешма статусын расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының түбәндәге торак пунктлары: Богородский авыл җирлеге Көек авылының Азовская, Балтийская, Каспийская, Ясная Поляна, Тихая, Охотская урамнары, Молодежная урамының д.1,3,5,7,21,21/1,25,27 номерлы йортлары - гарантияләү оешмасының эшчәнлек зонасы булуын билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов